СОВЕТ ЦИПЬИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 10, с. Ципья, 422243

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕПЬЯ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин ур., 10 нчы йорт, Чепья а., 422243

Тел.: (84368) 3-43-41, факс: (84368) 3-43-41. E-mail: Cip.Blt@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ**

28 июль 2025 ел № 158 Чепья

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең 20.12.2024 ел, № 141 «Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлегенең 2025 елга бюджеты һәм 2026 һәм 2027 еллар план чоры» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Авыл җирлеге баш бухгалтерының Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджетына 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге Советы карар кабул итте:: Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге Советының «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Чепья авыл җирлеге бюджеты турында»2024 елның 20 декабрендәге 141 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1нче статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1. 2025 елга Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга.:

1) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 13 017, 170 мең сум итеп.

2) Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 13 017, 170 мең сум итеп;

3) бюджет чыгымнары күләмен авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар исәбеннән; авыл җирлеге бюджетына күчерелә торган гражданнарның үзара салым акчалары исәбеннән арттырырга.

4) Балтач муниципаль районының Чепья авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0,00 мең сум күләмендә.

2. 1,3,5,7 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә".

Чепья авыл советы башлыгы А.Г.Нотфуллин